КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче
Өч Нарат торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

25.11.2021 №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Иске Икшермә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, Иске Икшермә авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 25 октябрендәге 35 номерлы карары нигезендә, 2022 нче елда Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Өч Нарат торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) – Өч Нарат авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 73 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 41кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның 41е тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0_е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Иске Икшермә авыл җирлегенең Өч Нарат торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. 2022 нче елда Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге Өч Нарат торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) Өч Нарат авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау;” дигән сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Җыен нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче:
Иске Икшермә авыл
җирлеге Н.Н.Нурмөхәмmәтов